ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
Кукмара муниципаль районы
Важашур авыл җирлеге Советы

# КАРАР

2020 елның 28 январь 3 номерлы

Важашур авыл җирлеге Советының «Җир салымы турында» 2013 елның 22 ноябрендәге 32 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Салым кодексының 31 бүлеге нигезендә Важашур авыл җирлеге карар бирде:

1. «Җир салымы турында» 2013 елның 22 ноябрендәге Важашур авыл җирлеге Советының 35 номерлы карарына (Важашур авыл җирлеге Советының 2014 елның 24 ноябрендәге 32 номерлы, 2015 елның 28 маендагы 25 номерлы, 2015 елның 26 ноябрендәге 12 номерлы, 2017 елның 27 июнендәге 9 номерлы, 2018 елның 7 ноябрендәге 27 номерлы, 2018 елның 29 ноябрендәге 31 номерлы, 2018 елның 20 декабрендәге 34 номерлы, 2019 елның 28 ноябрендәге 22 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 пунктның 4 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4) кадастр хакының 0,1% ы – 2017 елның 29 июлендәге «Гражданнар тарафыннан үз ихтыяҗлары өчен бакчачылык һәм яшелчәчелек алып бару һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында»гы 217-ФЗ номерлы Федераль законда каралган эшмәкәрлек эшчәнлегендә кулланылмый торган, шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару, бакчачылык яки яшелчәчелек алып бару өчен сатып алынган (бирелгән) җир кишәрлекләренә, шулай ук гомуми кулланылыштагы җир кишәрлекләренә карата;»

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында түбәндәге адрес буенча урнаштырырга: www.pravo.tatarstan.ru, шулай ук Важашур авыл җирлеге торак пунктлары территориясендә махсус мәгълүмат стендларында да.

3. Әлеге карар Россия Федерациясе Салым кодексының 5 статьясы нигезендә үз көченә керә.

Важашур авыл җирлеге
башлыгы: Иванов П.Л.